КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 26 март г.Казань № 273

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1001 нче; 2016 ел, 7 октябрь, 725 нче; 2017 ел, 15 август, 581 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 953 нче; 2018 ел, 31 май, 411 нче; 2019 ел, 15 гыйнвар, 4 нче; 2020 ел, 3 март, 162 нче; 2020 ел, 21 апрель, 310 нчы; 2020 ел, 27 июль, 627 нче; 2021 ел, 1 октябрь, 942 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1358 нче; 2022 ел, 22 февраль, 154 нче; 2022 ел, 18 август, 854 нче; 2023 ел, 6 апрель, 419 нчы; 2023 ел, 3 июль, 773 нче; 2023 ел, 17 август, 984 нче; 2024 ел, 26 гыйнвар, 34 нче; 2024 ел, 5 август, 621 нче; 2025 ел, 8 сентябрь, 675 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга һәм алар белән Министрлык һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр хезмәткәрләрен, шулай ук урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә бурычларны хәл итүдә ярдәм күрсәтүче башка затларны бүләкләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин